СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**“16” октябрь 2019 ел** **№ 98**

**Урта Курса авыл җирлеге Советының “Физик затларның мөлкәтенә салым турында” 2015 елның 3 ноябрендәге 11 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясының беренче өлеше һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә Урта Курса авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Урта Курса авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 ноябрендәге 11 номерлы «Физик затларның мөлкәтенә салым турында» Карарына (Урта Курса авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 ноябрендәге 74 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 2 пунктында:

1.1.1. 2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) 0,2 процент:

фатирга, фатирның өлешенә;

бүлмәгә карата;»;

1.1.2. 3нче пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«торак йортлар, торак йортларның өлешләре;».

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салымны исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан, игълан ителгән көннән бер ай үзганнан соң гына үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Арча хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина